МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ
ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ
И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ
ЭШЛӘРЕҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ
ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

____30.11.__________2021 № __403____

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 28.01.2019 № 38 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы 28.01.2019 № 38 боерыгы (Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы 29.05.2019 № 216, 04.12.2019 № 435 боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:
«Министрлык эшчәнлеген иҗтимагый контрольдә тоту»;
2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2.2. Иҗтимагый советның бурычлары булып түбәндәгеләр тора:
Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү һәм муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдә аларның нәтиҗәләрен бетерү, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм уздыру буенча, Дәүләт янгынга каршы хезмәте көчләре белән янгын сүндерүне оештыру буенча, Гражданнар оборонасы

буенча муниципальара һәм төбәк дәрәҗәсендә чараларны гамәлгә ашыруны оештыру, Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрне эзләү һәм коткару буенча тәкъдимнәр әзерләү;

Министрлык карарларын кабул иткәндә җәмгыять фикерен исәпкә алу механизмын камилләштерү;

Министрлык эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча җәмәгатьчелекнең мәгълүматлылыгын арттыру;

җәмгыятьтә коррупцион гамәлләргә түземсезлек булдыру.»;

2 нче бүлекне түбәндәге эчтәлекле 2.4 пункты белән тулыландырырга:

«2.4. Әлеге максатларга ирешү һәм куелган бурычларны хәл итү өчен Иҗтимагый совет:

Татарстан Республикасы халкын һәм территориясен табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен хәл итүдә дәүләт сәясәтен камилләштерү һәм муниципальара һәм региональ характердагы гадәттән тыш хәлләрдә аларның нәтиҗәләрен бетерү, авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыру һәм уздыру буенча, Дәүләт янгынга каршы хезмәте көчләре белән янгын сүндерүне оештыру буенча, Гражданнар оборонасы буенча муниципальара һәм төбәк дәрәҗәсендә чараларны гамәлгә ашыруны оештыру, Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләрне эзләү һәм коткару буенча тәкъдимнәр әзерли;

коррупциягә каршы эштә катнаша;

2014 ел 21 нче июль № 212-ФЗ «Россия Федерациясендә иҗтимагый контроль нигезләре турында» Федераль закон нигезендә Иҗтимагый совет утырышында алдан фикер алышудан башка кабул ителә алмый торган башкарма орган тарафыннан эшләнә торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза үткәрүне оештыра;

Министрлык тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфаты мониторингында катнаша;

Министрлыкның дәүләт сатып алуларының нәтиҗәлелеген бәяләүдә катнаша;

дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс үткәрү буенча һәм дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче дәүләт граждан хезмәткәрләрен аттестацияләү буенча комиссия эшендә катнаша.»;

3.6 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«әлеге Нигезләмәнең 6.6 пунктында каралган нигезләрнең булуы.»;

3.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«аның мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынуы барлыкка килүе.»;

3.8 пунктта:

беренче абзацта «яисә рәис урынбасарын» сүзләрен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «яисә рәис урынбасарына» сүзләрен төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле 6 нчы бүлек белән тулыландырырга:

«6. Иҗтимагый советта мәнфәгатьләр каршылыгы

6.1. Мәнфәгатьләр каршылыгы - Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы үз бурычларын (вәкаләтләрне үтәү) тиешенчә, объектив һәм гадел башкаруга йогынты ясый яки ясый ала торган һәм Иҗтимагый совет әгъзасының шәхси кызыксынуы һәм Иҗтимагый советның максатлары, бурычлары арасында барлыкка килә яисә килә ала торган хәл.

6.2. Иҗтимагый совет әгъзасының үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруның объективлыгына һәм гаделлегенә йогынты ясый яки ясый ала торган шәхси кызыксынуы астында, Иҗтимагый совет әгъзасы тарафыннан үзе яки өченче затлар өчен акча, кыйммәтләр, башка мөлкәт, шул исәптән мөлкәт хокуклары яки хезмәт күрсәтү рәвешендә керемнәр алу мөмкинлеге күз алдында тотыла.

6.3. Иҗтимагый совет әгъзасы Иҗтимагый совет рәисенә һәм министрга мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булгач та, язмача хәбәр итәргә, ә Иҗтимагый совет рәисе бу хакта Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә мәгълүмат бирергә бурычлы.

Иҗтимагый совет рәисе министрга язма рәвештә һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына мәнфәгатьләр каршылыгы яки аның барлыкка килү мөмкинлеге турында, бу хакта аңа билгеле булгач та, хәбәр итәргә бурычлы.

6.4. Мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган Иҗтимагый совет әгъзасында шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе яисә Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча, шулай ук Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы билгеләгән тәртиптә министрга мәнфәгатьләр каршылыгы ягы булып торучы Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору яисә туктату турында тәкъдим кертү юлы белән чаралар күрергә бурычлы.

6.5. Иҗтимагый совет рәисе яки Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы Иҗтимагый совет эшчәнлегенең коррупциоген куркынычына бәя бирәләр һәм Коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә Иҗтимагый совет әгъзаларының катнашуына юл куймау максатларында аларны минимальләштерү буенча чаралар күрәләр.

Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет рәисе өч эш көне дәвамында бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый Палатасына язма рәвештә хәбәр итә.

Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты турында мәгълүм булган Иҗтимагый совет әгъзалары өч эш көне дәвамында бу хакта министрга һәм Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасына язма рәвештә хәбәр итәләр.

6.6. Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты

турында мәгълүмат алу очракларында Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасының Иҗтимагый совет эшендә катнашуын туктатып тору турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктатып тору турындагы карары Министрлык боерыгы белән 30 көнлек вакытта расланырга тиеш.

6.7. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган хәлләр бетерелмәгән очракта яисә Иҗтимагый совет рәисенең коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләрен үз эченә алган эшчәнлектә катнашу факты расланса, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен туктату турындагы карары Министрлык боерыгы белән 30 көн эчендә расланырга тиеш.

6.8. Иҗтимагый совет әгъзасында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килүгә китерә торган шартлар бетерелгән (расланмаган) һәм (яки) Иҗтимагый совет әгъзасының коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын бозу билгеләре булган эшчәнлектә катнашу факты расланмаган очракта, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы министрга Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен кайтару турында тәкъдим кертә.

Министрның Иҗтимагый совет әгъзасы вәкаләтләрен кайтару турындагы карары Министрлык боерыгы белән 30 көнлек вакытта расланырга тиеш.».

2. Биредәге Боерыкны үтәү контролен үземә калдырам.

Министр вазыйфаларын
башкаручы Т.В. Кәримуллин